РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН

ГЛАВА САБИНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ

САБА МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БАШЛЫГЫ

ПОСТАНОВЛЕНИЕ КАРАР

28.02.2020 № 32-п

Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Башлыгының 2015 елның 10 декабрендә кабул ителгән 178-п номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Советының вазыйфаи затлары тарафыннан гражданнар мөрәҗәгатьләрен карау һәм шәхси кабул итү тәртибенә үзгәрешләр кертү турында

“Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү һәм миграция өлкәсе һәм эчке эшләр өлкәсендә дәүләт идарәсен үзгәртеп коруга бәйле рәвештә, “Россия Федерациясендә алгарышлы социаль-икътисадый үсеш территорияләре турында” Федераль законның 22 статьясындагы 2 өлешенең 2 пунктының үз көчен югалтуын тану турында” 2018 елның 27 декабрендәге 528-ФЗ номерлы Федераль закон һәм “Татарстан Республикасында гражданнарның мөрәҗәгатьләре турында “Татарстан Республикасы Законының 7 статьясына үзгәреш кертү хакында” 2019 елның 1 мартындагы 10-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы нигезендә,

КАРАР БИРӘМ:

**1.** Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Башлыгының “Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Советының вазыйфаи затлары тарафыннан гражданнар мөрәҗәгатьләрен карау һәм шәхси кабул итү тәртибен раслау турында” гы (Саба муниципаль районы Башлыгының 2018 елның 31 маендагы 90-п номерлы карары редакциясендә) 2015 елның 10 декабрендәге 178-п номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Советының вазыйфаи затлары тарафыннан гражданнар мөрәҗәгатьләрен карау һәм шәхси кабул итү тәртибенә түбәндәге үзгәрешне кертергә:

**1.1**. 10.3 пунктының икенче абзацында “федераль башкарма хакимият органының миграция өлкәсендә хокук куллану функцияләрен, тикшерү, күзәтү һәм дәүләт хезмәтләре күрсәтү функцияләрен гамәлгә ашыручы территориаль органы” сүзләрен “федераль башкарма хакимият органының эчке эшләр өлкәсендәге территориаль органы” сүзләренә алмаштырырга.

**2.** Әлеге карарны Интернет челтәрендә - Татарстан Республикасының Хокукый мәгълүматлар турындагы http://pravo.tatarstan.ru рәсми порталында һәм Саба муниципаль районының http://saby.tatarstan.ru рәсми сайтында бастырып чыгарырга.

Саба муниципаль
районы Башлыгы Р.Н. Минниханов